МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.11.2022** Казан шәһәре **№380**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында хезмәтләре ришвәтчелек куркынычы белән бәйле булган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәт чорында үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында хезмәтләре ришвәтчелек куркынычы белән бәйле булган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре хезмәт чорында үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әйдәүче вазыйфалар төркеменең «белгечләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Мәгълүмат ресурслары, икътисади анализ һәм социаль үзгәрешләр буенча тикшеренүләр идарәсе башлыгы – 1 берәмлек;

Эшкуарлыкны үстерү идарәсе башлыгы – 1 берәмлек;

көндәшлекне үстерү бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
сәнәгать паркларын үстерү бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
мәгълүмат ресурслары һәм технологияләре бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисади хәлен мониторинглау бүлеге башлыгы – 1 берәмлек;
эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге башлыгы урынбасары – 1 берәмлек;
мәгълүмат ресурслары һәм технологияләре бүлеге башлыгы урынбасары – 1 берәмлек;
мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгы урынбасары – 1 берәмлек;
муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисади хәлен мониторинглау бүлеге башлыгы урынбасары – 1 берәмлек;
юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 берәмлек;
юридик бүлекнең әйдәп баручы консультанты – 2 берәмлек;
икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;
инвестиция сәясәте һәм проектларга икътисади анализ бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 3 берәмлек;
инвестиция сәясәте һәм проектларга икътисади анализ бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;
лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;
лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;
көндәшлекне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;
көндәшлекне үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 2 берәмлек;
сәнәгать паркларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 берәмлек;
эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 2 берәмлек;
инновацияләрне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек».

**Татарстан Республикасы Премьер-министры**
**урынбасары – министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**